
# Габдулла Тукай

**26 апреля 1886-15 апреля 1913**




великий татарский народный поэт, литературный критик, публицист, общественный деятель и переводчик.



# «ТУГАН ТЕЛ»

## музыка НАРОДНАЯ

1.И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!

Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

2.Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,

Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең,

кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.

4.И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:

ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, ходам!



1799-1837





1886-1913

Тукай! На небосклон мировой поэзии он взошёл крупной и яркой звездой, и, запрокинув голову, сразу увидишь эту звезду в созвездии Пушкина. Почему именно Пушкина? А потому, что очень многое роднит этих поэтов разных времён и разных языков.



- Зимою ночью я, босой, в одной рубашке, выхожу на двор и потом иду к двери, чтобы войти в дом. Открыть дверь в избу зимой трудно не то что ребёнку, но даже взрослому человеку. Я, естественно, не могу её открыть и стою, пока ноги мои не примёрзнут ко льду.
"Благодетельница " моя, рассуждая: "Небось, не околеет, подкидыш!", держала меня за дверью и впускала в избу с ругательствами, когда ей заблагорассудится».







# КЫЗЫКЛЫ ШӘКЕРТ

- Әйдәле, акбай! Өйрән син, арт аягың берлә тор;
Аума, аума! Туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!

- Ник газаплыйсың болай син, мин әле бик кечкенә;
Мин туганга тик ике айлап булыр, йә өч кенә.

Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә;
Шул болыннарда ятасым, шунда ауныйсым килә.

- Ах, юләр маэмай! Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул;
Картаеп каткач буыннар, - эш белү уңайсыз ул!

# Тукай йолдыз.

- 1.Мәктәпкә барам мин көндә
- Кулга китаплар тотып.
- Күңелемне яктыртам мин
- Тукай шигырын укып.
- Кушымта:
- Җырлары йөрәк түремдә,
- Шигерләре күңелдә.
- Тукай дигән йолдыз балкый
- Балачагым күгендә.
- 2.Рәсемнән елмая Тукай
- Бөтен мәктәпне нурлап.
- Безнең күңелләр нурлана
- Тукай җырларын җырлап.
- Кушымта:



# Театр

слова Габдуллы Тукая

музыка Захида Хабибуллина



# **Театр.** (Габдулла Тукай сузлэре)

- 1.Халыкка дәрсе гыйбрәттер театр, театр,
- Күңелдә йоклаган дәртне уятыр, уятыр.
  Театр — яктылыкка, нурга илтә, нурга илтә,
  Кире юлга җибәрми, уңга илтә, уңга илтә.
  Кушымта:
  Театр — яктылыкка, яктылыкка,
  нурга илтә (2т )
  2.Театр көлдерәдер, уйнатадыр, уйнатадыр,
  Тагы үткән гомерне уйлатадыр, уйлатадыр.
  Күрерсең анда үз хәлең, көләрсең, көләрсең
  Көләрлек булса, булмаса — еларсың, еларсың.
  Кушымта:
  Театр — яктылыкка, яктылыкка,
  нурга илтә (2т )




шурале

# Тукай абый.

- 1.Барыбызда без укыйбыз
- “Туган тел”не җырлыйбыз
- Бу Тукай абый бүләге
- Иң гүзәл бер җыр дибез.
- 2. Әкиятләрен сөйләп, тыңлап
- Телләребез ачыла
- “Су анасы”, “Шүрәлеләр”
- Безнең дуслар барсыда.

# «Безнең гаилә» (1910)

- Әткәй, әнкәй, мин, апай,
- әби, бабай һәм бер песи —
Безнең өйдә без җидәү:
- безнең, песи — җиденчесе.

Бергә ашый, чәй эчә,
- безнеңлә бергә йоклый ул,
Хезмәте дә бар:
- өйне тычкан явыздан
- саклый ул.

## БӘЙРӘМ БҮГЕН

Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген.
Нәрсәдән бу? — Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм
бүген!

Бер мөкаддәс хис белән һәрбер кеше хәйран бүген;
Уйный сазым да минем бәйрәм көен, бәйрәм бүген!

Яр башыннан тыңладым мин бер суның дулкыннарын:
Сөйләшәләр үзара: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Тыңладым әкрен генә искәндә бәйрәм көн җилен;
Ансы да сөйли тагын: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

# Габдулла Тукай

## 26 апреля 1886-15 апреля 1913



